وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№17 (160). 26 октябрь 2012 / 11-зөлхиҗҗә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Мәдрәсә мөгаллимәләрендә әдәп-әхлак мәсьәләсе

▷ 2,4 ◁



Идел буенда ислам сәнгатенең башлангыч чоры үзенчәлекләре

▷ 2,4 ◁



"Алтын урта" акция уздырды

▷ 3 ◁

# Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!

## Корбан бәйрәме уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.МИҢНЕХАНОВНЫҢ

## МӨРӘҖӘГАТЕ



**Мөхтәрәм Татарстан мөселманнары!**

Сезне мөселманнарның иң нурлы, иң күркәм бәйрәмнәреннән берсе - Корбан гаете белән ихлас күңелдән тәбрик итәм. Мөселманнарны Исламның рухи чыганакларына өндәүче, дөньядагы барлык диннәр өчен уртак булган шәфкать-мәрхәмәт һәм гаделлек кебек югары әхлакый һәм гуманлылык идеалларына тирән хөрмәт хисләре тәрбияләүче, вакыт узган саен балкышы көчәя, кадере арта барган бу зур тантананың хәзерге җәмгыять нигезләрен ныгытуда әһәмияте һич кимеми, киресенчә, үсә генә бара.

Мөкатдәс хаҗ төгәлләнгән вакыт - Корбан гаете кеше календендәге рухи яңарышны чагылдыра, кардәш-ыру, фәкыйрь-мохтаҗлар турында кайгырту зарурлыгын, Аллаһының рәхмәте чиксез киң булуын искәртә.

Төрле милләтләр һәм диннәр арасын суытмыйча, алардагы татулык, хезмәттәшлек рухын, уңай мөнәсәбәтләрне саклау, һичшиксез, республикабызның гаять зур казанышы булып тора. Безгә ата-бабаларыбыз васыять иткән милләтара һәм динара тынычлыкның югалуына юл куярга ярамый. Татарстан мөселманнары киләчәктә дә диннәр арасында үзара хезмәттәшлекне, тынычлыкны, иминлекне ныгытуга үзләреннән саллы өлеш кертерләр, дип ышанам.

Корбан бәйрәме һәрберебезгә көч-егәр, илһам өстәсен, гаиләләребезгә бәрәкәт, бәхет һәм муллык китерсен!

Сезгә чын күңелдән рухи бөтенлек, матур тормыш һәм игелекле эшләрегездә зур уңышлар телим!

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. МИҢНЕХАНОВ**

# Яулык кию дөньяви дәүләт кануннарын бозмый!

**Россия күләмендә җәнҗал килеп чыгу өчен янә хатын-кызлар киеме сәбәп булып куйды. Юк, бу юлы "йолдыз"лардан берәү дә чишенеп күрсәтмәде күрсәтүен. Бары тик Ставрополь краендагы бер мәктәп директоры укучыларга дәресләргә яулык киеп килүне тыйды. Шуннан соң бу балаларның әти-әниләре һәм Ставрополь мөфтие прокуратурага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды. Прокуратура тикшерү эшләре башлады.**

Бу вакыйга уңаеннан, төрле трибуналардан "дөрес эшләгән" һәм "без моңа каршы" дип, төрле шау-шулы белдерүләр дә яңгырады.

Россиянең Мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов Дәүләт Думасы утырышы вакытында, илебезнең "Мәгариф турында"гы закон проектын беренче укылышта тикшергәндә: "Миңа билгеле булганча, Ставрополь краендагы, моңа кадәр аның турында сүз алып барылган конкрет бу мәктәптә, кызлар 1 сентябрьдән башлап мәктәпкә яулыктан йөргәннәр. Бу - мәктәп кагыйдәләренә һәм гомум кабул ителгән тәртипләргә һич кенә дә каршы килми", - дип белдергән иде.

- Без гаиләләрнең дини һәм мәдәни үзенчәлекләре мәктәпнең дөньяви характерда булуына каршы килмәскә, конфликтка бармаска тиеш дип исәплибез. Киләчәктә мондый низагларга юл куймас өчен хокукый шартлар төзербез дип уйлыйм, - дип билгеләп үтте Д.Ливанов.

Һәм шуннан соң, "Океан артындагы" төрле хокук яклау оешмалары һәм кайбер журналистлар министрга үзләренең ачуларын яудырырга тотындылар. Алар, мөгаен, Россиянең Мәгариф һәм фән министры Конституцияне бозсын һәм кызлар яулык ябып мәктәпкә килүне тыйсын дип исәпләгән булганнардыр инде.

Мәктәп җитәкчелеге, үз чиратында, барысын да уку йорты уставына кайтарып калдыра. Ә анда укучыларның тышкы кыяфәтенә бердәм таләпләр куелуы турында язылган икән, имеш. Кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары китергән хәбәрләр буенча, булып үткән бу вакыйгага Президентның балалар хокуклары буенча вәкиле Павел Астахов та аңлатмалар биреп узган. Ул: "Мәктәп җитәкчелегенең чаманы белми арттырып җибәргәнлеге ачык күренеп тора, ә яулык, бу очракта, бернинди дә күрексез атрибут булып исәпләнә алмый", - дип исәпли. Астахов, конфликт толерантлык һәм бер-береңнең карашларына сабырлык белән карау рухында чишелер, дип өметләнә.




Россия Президенты Владимир Путин Гомумроссия халык фронты активлары белән очрашуы вакытында мәктәпләрдә хиҗап киеп йөрүгә үз мөнәсәбәтен белдерде.

- Һәрвакытта да кешеләрнең дини хисләренә зур хөрмәт белән карарга кирәк, бу дәүләтнең эшчәнлегендә, нюансларда чагылыш табарга тиеш, - дип әйтте В.Путин. - Без - күпконфессияле дәүләт, ләкин, гомуми дөньяви дәүләтнең үз кагыйдәләре бар. Бездә чиркәү дәүләттән аерылган.

Аның сүзләре буенча, башта бу мәсьәләнең Европа илләрендә ничек чишелүен карарга кирәк, аннан соң "һәммәсе дә ачыкланыр". "Барысын да тыныч, кабул ителешле формаларда хәл итәргә, беркемне дә рәнҗетмәскә кирәк", - дип өстәде ул.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: кайбер Европа илләрендә хәтта хатын-кыз полицейскийлар да хиҗап киеп йөри.

Аннан тыш, ил башлыгы регионнарга мәктәпләрдә бердәм форма үрнәкләре кертү турында да уйларга киңәш итте.

Кемгәдер бу артык тупас һәм вульгар да булып күренергә мөмкин, шулай да, Россия телеканалларында узган уку елы ахырында күрсәтелгән тапшыруларны бар ил белән ничек итеп хәйран калып "тикшергән"нәрне искә төшерик әле. Бу тапшыруда илебезнең мәктәп укучыларының чыгарылыш кичәләрендәге күлмәкләрен күрсәттеләр. Ул күлмәкләр бернинди дә чикләрне белми торган дәрәҗәдә иде. Бер генә мәктәп директоры да "Соңгы кыңгырау"га андый "күлмәкләр" киеп килүне тыймады...

Үзенең этнокофессиональ күптөрлелеге белән үзенчәлекле Россиядә, аек акыл барыбер өскә чыгар һәм үзенең бай тарихы һәм гыйффәтлелеккә үтә сакчыл карашы белән билгеле борынгы халыклар мәдәнияте бу ил халкын "шәрәләндерергә" ирек бирмәс дип ышанасы килә.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

## ЯҢАЛЫКЛАР

**В.ПУТИН МӨСЕЛМАННАРНЫ КОРБАН БӘЙРӘМЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫ**

**"Йөз еллар дәвамында әлеге бәйрәм иң игелекле һәм якты хисләр белән сугарылган.** Ул кешеләрне якынайтуга, җәмгыятьтә яхшылык, кече күңеллелек һәм бер-береңне хөрмәт итү кебек идеалларның раслануына хезмәт итә, Исламның мәңгелек кыйммәтләренең тирәнлеген ача.

Россиянең мөселманнар берләшмәсе динара һәм милләтара диалог үсешенә, ил халыклары бердәмлегенә зур өлеш кертә. Алар хәйрия эшендә, гаилә кыйммәтләрен торгызуда, экстремизмга һәм түземсезлеккә каршы торуда актив катнаша.

Тагын бер кат сезне бәйрәм белән котлыйм. Сезгә сәламәтлек, бәхет һәм барлык яхшы башлангычларда уңышлар телим", - диелә котлауда.

**ХӨКҮМӘТ ҖӘМӘГАТЬ УРЫННАРЫНДА ТӘМӘКЕ ТАРТУНЫ ТЫЯ ТОРГАН ЗАКОННЫ ХУПЛАДЫ**

**Россия хөкүмәте җәмәгать урыннарында тәмәке тартуны тыю турындагы закон проектын хуплады, дип хәбәр итә РИА "Новости" мәгълүмат агентлыгы.**

Дәүләт Думасында депутатлар аны кабул итсәләр, документны президент караячак. Ул кул куйгач, яңа канун үз көченә керәчәк.

Россия премьер-министры Дмитрий Медведев закон проектының кабул ителүе илебезгә, башка илләрдәге кебек үк, цивилизацион юнәлештә барырга ярдәм итәчәк, дип әйтә.

Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан эшләнелгән закон проекты дәүләт учреждениеләрендә, белем бирү һәм мәдәният биналарында, спорт объектларында, җәмәгать транспортында, тимер юл вокзаллары, автовокзаллар, метро, аэропортларда тәмәке тартуны этаплап тыюны күздә тота. Шулай ук җәмәгать туклануы биналарында, эш урыннарында, күп фатирлы йортларның гомуми кулланылыш бүлмәләрендә, пляжда, балалар уйный торган территорияләрдә, медицина учреждениеләрендә һәм санаторияләрдә, еракка баручы поездларда һәм судноларда, авиатраспортта, базарларда, сәүдә итү урыннарында тәмәке тартуны тыю үз көченә керергә мөмкин.

**БУА МӘДРӘСӘСЕ БӘЙГЕ УЗДЫРА**

**Буа мәдрәсәсе район мөхтәсибәте, районның мәгариф бүлеге һәм Мәктәптән тыш эшләр үзәге белән берлектә Корбан гаете уңаеннан мәктәп яшендәге балалар арасында "Минем мәчетем" дип исемләнгән рәсем бәйгесе игълан итте. Ул 20 октябрьдән 20 ноябрьгә кадәр үткәрелә.**

Бәйгенең максаты - балаларны татар халкының рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру, аларның иҗади кызыксынуларын үстерү, талантларын ачарга ярдәм итү.

Бәйгедә алтыдан алып уналты яшькә кадәргеләр катнаша ала. Бәйге Корбан ашы белән төгәлләнәчәк. Иң яхшы эшләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак.

Рәсемнәр Буа шәһәре, К.Либкнехт урамы, 79 йорт (Буа мәдрәсәсе) адресы буенча кабул ителә. Сораулар өчен тел.: +7 (84374) 3-70-71, 89274101412 (Рәшид хәзрәт).

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# МӘДРӘСӘ МӨГАЛЛИМӘЛӘРЕНДӘ ӘДӘП-ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘСЕ

**Кешеләргә бер-берсен аңларга ярдәм итә торган иң тәэсирле чара - әңгәмә. Кешеләр арасында, шул исәптән мөгаллимә белән аның талибәләре (студенткалары) арасында да, үзара симпатиянең төп шарты - ягымлы мөгамәлә һәм алар белән йомшак итеп сөйләшү. Безнең бабаларыбыз юкка гына: "Татлы тел еланны да оясыннан чыгарыр", - димәгәннәр инде. Ягъни, ягымлы, татлы тел аша иң көйсез, иң үзсүзле бала белән дә үзара дустанә мөнәсәбәтләр урнаштырырга була.**



Сыйныфтагы һәр як та, мөгаллимә дә, талибәләр дә, үз аралашу манераларына зур игътибар бирергә тиешләр.

Тәрбияле кеше үз сүзләре белән әйләнәтирәсендәге кешеләрнең каефен төшермәскә, аларның күңелләренә яра салмаска; киресенчә, ягымлы, йомшак мөгамәләсе белән, аларның күңелләренә шатлык өстәргә тиеш. Хатын-кызлар ир-атларга караганда күбрәк хискә бирелүчән, шуңа да, хатын-кызлар белән аралашкан вакытта, аларга дөрес мөгамәлә табу читенрәк. Тыңлаучыларны үзенә җәлеп итеп, матур итеп сөйли белүнең укытучы өчен иң кирәкле сыйфатларның берсе икәнлеген белгән ислам мөгаллимәсе өчен, үз сүзләреңне үлчәп кенә әйтә белү һәм аны дөрес файдалану - бик әһәмиятле.

Мөгаллимә өчен аның сүзләре - аның акыл һәм фикеренең чагылышы, аның халәтенең, гыйлемлелегенең, игелеклелегенең күрсәткече. Дәрес алып баручының ул дәресне алып бару манерасы, аның шәхесен, аның тәҗрибә һәм мәдәният дәрәҗәсен бик яхшы чагылдыра. Мөгаллимә авызыннан чыккан һәр сүз акыллылык һәм зирәклелек белән тулы булырга тиеш. Сөйләм һәрвакыт тотнаклы булырга тиеш, чөнки бар хаталар да, телнең тотнаксызлыгы аркасында килеп чыга. Сөйләм әдәпле һәм чынлап та үлчәнелгән булырга тиеш.

Мөгаллимә дәрес биргәндә, укучысына, алып барган әңгәмәсенә, ул вакыттагы вазгыятькә карап, нинди сүзләр, гыйбарәләр кулланырга кирәк икәнен исәпли белергә тиеш. Ләкин сүзләр ялган, чын күңелдән булмаганча ясалма булып яңгырамаска тиешләр. Яхшы әйтелгән сүз төрле ызгыш-талашны туктата алгандагы кебек үк, уйламый әйтелгән сүз дә, укучы өчен зур бәла чыганагы булырга мөмкин.

Мөгаллимә дәрестә психологик ялгышлар җибәрми кала алсын өчен, ул түбәндә күрсәтелгән сөйләм манераларын кулланырга тиеш.

*1. Җитди булырга, үзеңне йөгәнсез тотмаска.*

*2. Һәр сүзне дә уйлап әйтергә һәм аны урынлы кулланырга. Әңгәмә табигый тонда барырга тиеш.*

*3. Сүзләрне ачык, мәгънәле итеп әйтергә, тонны күтәрмәскә һәм кискен тавыш белән сөйләмәскә.*

*4. Артык әкрен, ишетелмәс тавыш белән сөйләмәскә, талибәләр йоклап китәрлек булмасын.*

*5. Артык күп мимика, жестикуляция кулланып сөйләмәскә.*

*6. Талибәләрне яхшы үзләштерелгән материал өчен мактаганда яки аларның уңышсызлыкларын искә алганда, кыска гына сөйләргә.*

*7. Сүзлекләрдән алынган гыйбарәләр белән тулы, артык купшы тел белән сөйләмәскә тырышырга, төрле чагыштырып күрсәтү мисаллары куллану - яхшырак.*

*8. Талибәләрне үзегезне озаклап тыңлап утырырга мәҗбүр итү - яхшы түгел. Кыз балаларга, үсмерләргә, өлкән хатын-кызларга аларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып мөрәҗәгать итәргә.*

*9. Гел үзегез генә сөйләп тормаска, талибәләрнең җавапларын һәм өстәмәләрен дә игътибар белән тыңларга.*

*10. Үз укучыларыгыз сөйләгәндә, аларның сүзләрен кирәксезгә бүлмәскә, әгәр дә инде, андый хата җибәргәнсез икән, алардан моның өчен гафу үтенергә.*

Бу кагыйдәләрне үтәгән кеше, үз фикерләреңне дөрес итеп чагылдыра һәм аңлата алу, сөйли белү - Аллаһның үз колларында биргән, бәя биреп бетергесез олуг рәхмәте икәнен аңлауга ирешә.

Дәресләргә беренче тапкыр килгән күпчелек, анда өйрәнелә торган предметларның күплегеннән, андагы гарәп сүзләренең яңгырашыннан куркып калалар һәм бу белемнәрне алу безнең көчебездән килми дип әйтеп куялар. Мондый ялгышлык өлкәннәрдә дә, балаларда да була. Кешеләр

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Идел буенда ислам сәнгатенең башлангыч чоры үзенчәлекләре

**Аллаһның Берлеген һәм Бердәнберлеген аңлаткан тәүхид мөселман сәнгатендә бердәмлектәге күптөрлелек буларак чагылыш таба. Географик, тарихи һәм этник яктан күптөрле ислам дөньясындагы мөселман сәнгатенең берлеге - тулысынча анык, шул ук вакытта, аңа хас булган стильләрнең, сәнгать образларының, формаларының да. Гомуми (универсаль) сыйфатлар ислам эстетикасы, шәригать һәм гореф-гадәтләр нормаларына нигезләнгән аерым бер тип буларак характерлана.**



Мөселман сәнгатенең уртак сәнгать булып барлыкка килүе, теге яки бу халыкның исламга, ислам мәдәниятенә кушылу процессы белән бергә бара: сәнгатьнең яңа төрләре барлыкка килә, сәнгатьтә яңа эстетика, эчтәлек һәм форма концепцияләре, образлар һәм стильләр раслана. Алар җирле сәнгать традицияләре белән классик ислам сәнгате үрнәкләре кушылмасы (синтезы) булып төзеләләр, һәм нәтиҗәдә, аның милли һәм җирле формалары барлыкка килә. Бу кушылма сәнгать телендә, орнаменталь-декоратив принципларында, сурәтләүгә куелган таләпләрдә һәм стиль чагылышында ачыла.

Бабаларыбызның Ислам кабул итүләре, аларның мөселман сәнгатенең камиллеген үзләштерүенә юл ача. Татар сәнгате, башка мөселман халыклары сәнгате кебек үк, X гасырдан башлана, орнаменталь декоратив-гамәли һәм монументаль-декоратив иҗат формаларында үсеш ала. Сәнгать әсәрләренең стиль юнәлеше - ислам эстетикасының (аны "нәфасәт" дип тә атап йөртәләр) чикләрендә үсеш ала һәм аларны чагылдыра торган татар этник традицияләре җирлегендә милли үзенчәлеген барлыкка китерә. Татар сәнгате үсешенең күпгасырлык тарихы, аның гарәп, фарсы, төрки-мөселман дөньялары белән үзара йогынтылылык барышын чагылдыра. Шул ук вакытта, сәнгатьнең күп кенә нигезләре: материалларны эшкәртү үрнәкләре, технологияләре, иҗат принциплары һ. б.; бабаларыбыз булган борынгы төркиләр, урта гасыр болгарлары, кыпчаклар һәм Алтын Урда татарларының күчмә дала һәм утракигенчелек культураларына барып тоташа.

Мөселман сәнгате һәм татар мәдәниятенең этник традицияләре йогынтысында булган сәнгати һөнәрләрнең, һөнәрчелек житештерүнең үсешкә ирешкән булуын безнең көннәргә килеп җиткән декоратив-гамәли сәнгать төрләре дәлилли: каюлы күн (күн мозаикасы) һәм басма белән бизәкләнгән күн эшләмәләрен җитештерү, тукымаларны ука (алтын җеп) белән бизәү, чигү сәнгате, тукучылык һәм чәмчә (аппликация), җепкыр һәм күперткән җепкыр (филигрань), зәркән бизәү әйберләрен ташлар белән корлау ("полихром стиле"), агач йортларның бизәген уеп ясау һәм төсләр белән бизәү сәнгате һ. б.

Мөселман сәнгате барлыкка килүдә гарәп язма графикасы таралу да шактый зур роль уйный. Аның нигезендә хаттатчылык (каллиграфия) сәнгате - кульъязма китапта, татар шәмаилләрендә, каберташ язмаларында, биналар бизәүдә, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләрендә зур үсешкә ирешә.

Идел буендагы ислам сәнгатенең чыганаклары борынгы шәрык тамырларына таянган мөселман гарәп мәдәниятенең казанышларын кабул иткән югары болгар мәдәниятенә нигезләнә. Яңача нәфис сәнгать хәзинәләрен үзләштерү халык мәдәнияте җирлегенә таяна. Ләкин бу процесс эзлекле рәвештә бара: X-XII гасырларда элеккеге чорда барлыкка килгән сәнгать традицияләре дәвам итә. Бер үк вакытта, эчтәлеге ислам дине булган иҗади юнәлеш барлыкка килә. Шул уңайдан, кеше һәм тере җан ияләрен сурәтләү чиге канунлаштырылган хәдисләрдә һәм эстетик-философик концепцияләрдә (Әбу Насыйр әл-Фараби, Әбу Гали ибн Сина, Әбу Хәмид әл-Газзәли һ. б.) болгарларның Исламга кадәр мәдәниятендә кеше сурәтләрен төшерүгә тотнаклы мөнәсәбәте бер дә ят булмаган. (Кеше сурәтен ясау мәҗүсилек чорында да киң таралмаган, кеше рәсемнәрен төшерү идолларны ясаганда яисә кабилә башлыкларын күрсәткәндә файдаланылган.) Ислам кабул ителү белән кеше сурәте төшерү, сирәк булган искәрмәләрне исәпкә алмаганда, сәнгать әсәрләрендә очрамый, ә җанварлар һәм кошлар рәсемнәрен ясау - бары тик шартлы формаларда һәм бизәккә охшату рәвешендә (стилизация) генә була.

Ислам кабул иткәннән соң болгар сәнгатенең үзенчәлеге Урта гасырлар мөселман эстетикасының борынгы культлар, магик һәм мифологик күзаллаулар белән бәйле сурәтләү принципларында ачыла. Ләкин соңгысын, болгарларда мәҗүси традицияләрнең саклanып калуы белән түгел, ә урта гасырлар декоратив-гамәли иҗаты өчен закончалыклы сәнгать традицияләренең үсеше белән бәйләргә кирәк. Нәкъ менә традицияләр саклану сәбәпле, мотивлар һәм образлар, башкару техникасы, һәм еш кына бизәү композициясе үрнәкләре дә, халык осталары тарафыннан бер буыннан икенче буынга тапшырыла, шул рәвештә бүгенге вакытка кадәр сакланып килә. Шуңа да, исламга кадәр чорларда ук барлыкка килгән бизәү мотивлары, образлар һәм сюжетлардан чыгып, кайбер болгар сәнгатен өйрәнүче белгечләрнең, алар Көнчыгыш Европа мәҗүси мәдәнияте үрнәкләре булып торалар дип раслаулары - ялгыш дип исәпләргә кирәк. Киресенчә, Идел болгарлары сәнгать әсәрләрендә шул чорның иҗат теле сакланып калган археологик материаллары, бу дәүләтнең монотеистик идеологиясен бик ачык чагылдыралар.

Бу сәнгатьтә, үзендә сәнгати-эстетик критерийларның мөселман сәнгате белән уртаклыгын, һәм шул ук вакытта, халык традицияләре үсешен тәшкил иткән үзенчәлекле стиль барлыкка килә.

Идел буенда мөселман сәнгатенең барлыкка килүе чорында иске һәм яңа карашлар белән үзара тәэсирләшүе, политеистик ышанулар белән бәйле мифологик (риваяти) традицияләрнең әкренләп бетеп баруы, аларга алмашка ислам монотеизмының эстетик принципларын чагылдырган символик һәм шартлы-декоратив образлылыкның килүе күзәтелә. Шуның нәтиҗәсендә, тарихи үсеш белән бәйле һәм бары тик болгар сәнгате системасына хас булган сәнгать күренешләре барлыкка килә. Аның иҗади үзенчәлеге халыкның мәдәни һәм дини эстетик факторларның катнашмасы булып формалаша. Болгар сәнгатендә дәүләтне үзәкләштерүгә омтылучы тенденцияләр йөртүче, һәм, шуның нәтиҗәсендә, сәнгатьтә монотеистик юнәлеш булдырырга тырышучы хакимлек итүче болгар югары катламының сәнгать зәвыгы, һәм, төрки ыру-кабилә мохитендә барлыкка килгән этник мәдәният традицияләрне йөртүче халык массаларының зәвыгы

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# КЕШЕЛӘРНЕ ИСЛАМГА НИЧЕК ДӨРЕС ҮГЕТЛӘРГӘ?

**(Ахыры. Башы газетабызның 19 октябрь (№16) санында.)**

## Йомшак мөгамәлә

Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә: ***"Фиргавен янына китегез. Чөнки ул азгынлыкның аръягына чыкты. Әмма аның белән итагатьле итеп сөйләшегез, бәлки ул гыйбрәт алыр һәм акылга утырыр вә (гөнаһ кылудан туктар) куркыр"*** ("Та-һа" сүрәсенең 43-44 нче аятьләре), - дигән.

Бу боерык Муса пәйгамбәргә һәм аның абыйсы Һарунга әйтелгән булган. Фиргавен кешелек тарихында иң азгын һәм юлдан язган кеше булса да, аның белән йомшак итеп сөйләшергә кушыла.

Бер кеше мөэминнәр хакиме Һарун Рәшидкә кергән дә, аңа әйткән: "Ий хаким! Миңа үзеңә мөрәҗәгать итәргә рөхсәт ит!" Хаким рөхсәт иткән, һәм дә бу кеше Һарун Рәшидкә карата ярсулы шелтә һәм үпкә сүзләре белән кычкыра башлаган. Ярсудан хакимнең йөзе кызарып чыккан, һәм ул аңа: "Әй бәндә! Миннән начарракка Аллаһ синнән яхшыракны җибәргән", - дисә, аларга: "Аның белән йомшак итеп кенә сөйләшегез, бәлки ул үгет-нәсыйхәткә колак салыр, я куркыр", - дигән.

Аллаһ юлына өндәүче йомшак, миһербанлы тавыш белән сөйләшергә тиеш. Дорфа итеп сөйләшү безне кешеләрдән аера, һәм киресенчә, йомшак һәм игелекле мөгамәлә кешеләрне безгә тарта.

Коръәндә: ***"Аллаһ рәхмәте белән син аларга карата йомшак мөгамәләдә булдың. Әгәр дә син алар белән дорфа һәм каты бәгырьле булсаң, алар сине ташлап китәрләр иде"***, - диелгән.

Бу сүзләр Рәсүлуллаһка (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мөрәҗәгать итеп әйтелгәннәр. Әгәр дә инсаннарның иң яхшысы турында Аллаһы Тәгалә шулай әйтә икән, безнең кебек гади кешеләр турында ни әйтергә кирәк?

Әгәр дә без йомшак кына, аңлаешлы итеп кешеләргә хакыйкатьне аңлатабыз икән, аларның күңелләре дә бу хакыйкатькә омтылачак. Сәхабәләр тормышыннан, аларның берсе тупаслыкка йомшак мөгамәлә белән җавап биреп, һәм дә моның ул кешенең Ислам кабул итүенә сәбәп булуы турында бер мисал китерәм.

Мусаб бине Умайр Мәдинәгә барып, анда халыкны Исламга өнди башлагач, Мәдинә кешеләренең берсе, Усайд бине әл-Ходаер, аның яшьләрне бабаларының мәҗүси диннәреннән аеруына ачуы килеп, аны куып җибәрергә теләгән.

Ул корал тотып Мусабка барган һәм, әгәр дә ул кешеләрне иректә калдырмаса, аны җәзага тарту белән яный башлаган. Мусаб әдәпле, нәзакәтле итеп кенә аңа: "Сиңа утырып алып, безне тыңлап тору яхшырак булмас микән? Минем сүзләр сиңа ошап китсә, син аларны кабул итәрсең, ошамады икән инде - кире кагарсың", - дигән.

Усайд моның белән килешкән һәм сөңгесен җиргә кадап куеп торып, аның кырына килеп утырган. Мусаб аңа Исламның ни икәнен аңлата башлаган. Усайд алардан китеп барганда, инде мөэмин-мөселман булып китеп барган.

## Сабырлык

Сабырлык - Аллаһ юлына өндәүче ия булырга тиешле төп сыйфатларның берсе. Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) - Ул яраткан барчаның иң яхшысы. Гыйлемлелектә, тел камиллегендә, күркәм холыклылыкта аңа тиңнәр булмаган. Шуңа да карамастан, ул унөч ел буе мәккәлеләрне Аллаһ юлына өндәгән, тик аларның бик аз өлеше генә бу чакыруларга җавап биргән, һәм дә аңа туган шәһәрен ташлап китәргә туры килгән. Мәккәләләр мөэмин-мөселман булып киткәнче тагын бер генә ел да түгел, күп вакытлар үткән... Рәсүлуллаһның (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тәрҗемәи хәлен өйрәнгәндә, без аның бу юлда күпме мохтаҗлыклар, газаплар кичергәнен күрәбез. Ни өчен соң әле без, нибары бер тапкыр гына хак юлга чакырып, кешеләр безнең мөрәҗәгатькә колак салырга тиеш дип көтеп утырабыз?

Кешелек тарихындагы бар рәсүл һәм пәйгамбәрләр дә, еллар, кайвакыт, мәсәлән, Нух пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте булсын!) кебек, йөзләрчә еллар буена, үз халыкларын иманга өндәгәннәр, һәм бу эштә аларга очраган бар авырлыкларны сабыр гына кичергәннәр. Алар кичергәннең барысына да түзәргә безнең көчебездән килми, әлбәттә, тик бераз гына булса да, без аларга ошарга тырышырга тиешбез. Бу дөнья рәхәтлекләрен алыр өчен без авырлыкларга, мохтаҗлыкларга түзәбез бит. Әллә мәңгелек бәхеткә ирешү - безнең тарафтан бераз гына сабырлык күрсәтерлек тормыйммыни?

Һәр мөселманга да хакыйкатьне ирештерү җаваплылыгы салынган. Без һәрберебез дә, үз гаиләләребез әгъзаларын, туганнарыбызны, якыннарыбызны хак юлга өндәргә тиешбез. Әгәр дә без моны эшләмәсәк, моның өчен безгә Хисап көнендә җавап тотарга туры киләчәк. Кемдер минем тиешле белемнәрем юк, тавышым күркәм түгел дип каршы да килергә мөмкин. Ләкин үз балаңны булса да, мөгаллимгә, ул аны дин нигезләренә өйрәтсен өчен, алып барырга күп әйбер кирәкме? Әллә без вәгазьләр язылган китаплар, дисклар алып, үз балаларыбызга Ислам галимнәренең вәгазь-лекцияләрен укырга, тыңларга мөмкинлек бирә алмыйбызмы? Үзегезнең, балаларыгызның китапханәсендә, дисклар тупланмасында нинди китаплар һәм әсбаплар бар икәнен карап чыгыгыз әле. Әгәр дә сез анда дин турында бер генә китап та, диск та таба алмасагыз, ныклап уйланырга вакыт түгелме икән?..

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые**



## Мөселманнар – иң ышанычлы ирләр

**Галимнәр 15 яшьтән 59 яшькә кадәр булган 620 меңнән артык кешенең анкеталарын анализлаганнар. 30 илдән керүчеләрнең (индуистлар яшәгән Һиндстан белән Непалдан һәм будда динен тоткан Камбоджидан кала) күпчелеген я мөселманнар, я христианнар тәшкил иткән. Сорашу 8 ел дәвамында бара: 2000-2008 елларда, дип яза "Компьюлента" сайты.**

Тормыш корган мөселманнар өйләнгәнче җенси мөнәсәбәткә керүләрен христианнарга караганда 53 процентка, ә индуистлар 40 процентка азрак таныйлар. Яһүд һәм будда диннәрен тотучылар гаиләкорганчы җенси мөнәсәбәтләргә христианнарга караганда ешрак керәләр. Шуңа өстәп, башкалардан аермалы буларак, мөселманнар хатыннарына сирәгрәк хыянәт итәләр.

Тикшеренүчеләр, мөселманнар дини кагыйдәләрне башка дин вәкилләренә караганда катгый рәвештә үтиләр, дип нәтиҗә ясый. Шулай ук христианнардан һәм яһүдиләрдән аермалы буларак, мөселманнар күп очракта гаиләләрен яшьрәк чакта кора.

Мөселманнарның күпчелеге халыкның җенси нормаларына да йогынты ясый. Җәмгыятьтә мөселманнар санының бер процентка артуы, башкаларның нинди дин тотуларына карамастан, гаилә корганчы җенси мөнәсәбәтләргә керү очракларын ике процентка кимәтә.

"Дөньякүләм диннәр гаилә корганчы җенси мөнәсәбәткә керүне тыялар, ләкин кешенең үз-үзен тотуын формалаштыруда алар барысы да бертигез дәрәҗәдә көчле тәэсир итмиләр", дип нәтиҗә ясый Җинаятьләргә гадел хөкем чыгару колледжының Эми Адамчик җитәкчелегендәге тикшеренүчеләреннән Джон Джей (АКШ).

Мөселманнар зина кылу тыелуны башкаларга караганда катгыйрак үтиләр. Алар белән индуистлар гына тигезләшә ала, дип исәпли тикшеренүчеләр.

## Калебләребез ник гафиллектә?

**Ял көнемдә, Казанга барырга дип, юлга кузгалдым. Мәшләк авылына җиткәч танышымны очраттым. Без бер машинада бардык. Ул мине таныган, мин генә аны танымыйча интектем. Һәрвакытта күзләре янып торган, көчле, акчага да интекми яшәгән, тормышны яратучы бу ханым сулыгып, тартылып киткән.**

"И, кызый, яшь кенә көенчә энием вафат булды бит әле", - дип сүзен башлады ул. "Үлемнең яше, карты юк инде аның. Безгә бит әниләр йөздә, илледә дә әни булып кала", - дигән уй баштан йөгереп узды. Гөлсылу апаны (танышымның энисе) күптәннән яхшы беләм. Бер оешмада баш хисапчы булып эшләде. Фатирында булганым бар. Аларның ничек яшәүләрен күреп сокланып кайткан идем. - Менә, син дини белем алып йөрисең. Күп нәрсәләрне хәзер беләсеңдер. - Күп булмаса да, беләм инде. Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисе дә бар бит. Бишектән алып ләхеткәчә белем алырга кушкан. Дини белемнәрне күбрәк үзләштергән саен, тирәнрәк үтеп керсәң, үзеңне гел берни белмәгән кебек хис итәсең. Танышымның энисе юл фаҗигасенә юлыккан икән. Берүзе шушы кызын үстереп, укытып, олы тормыш юлына чыгарды. Кызын тудыруга ире белән аерылды. "Мин бит үзем акчаны табам, миңа нәрсәгә ир", - дип шаккаттыргән иде. "Нигә дип мин ирне ашатып, киемнәрен карап торырга тиеш. Минем бит болай да эшем авыр, җитәкчем дә мине хөрмәт итә, акчаны күп итеп түли". Акчаның күп булуы әйбәт анысы. Ул бит ишекләрне ачып керергә ярдәм итә. Гөлсылу апаның кызына әниеңә күп итеп догалар укып тор дип киңәш иттем. Үземнең сумкада һәрвакыт "Һәфтияк Шәриф" йөри. Аны алып биреп, "Фатиха" сүрәсен укы", -дидем. - Әниең сөенсен, хәзер аңа догалар гына булыша". "Адәм баласы Аллаһы Тәгаләне авыр кайгылардан соң яки берәр якын кешесен югалткан чагында гына исенә төшерә. Ә башка вакытагы алдын-артын карамыйча, дөнья куа, мәңгелеккә теге дөньяга барачагы һәм аңа әзерләнергә кирәклеге турында уйлап та карамый", - дигән уй башымнан йөгереп узды. Бу сүзләр дә хәзерге вакыттагы чынбарлык. Ахирәткә барачагын һәм аңа әзерләнү зарур икәнен күпләр аңламый. Әлегә безнең күбебез гафиллектә. Гел акча турында уйлыйбыз. Ата-ананы, олыларны, бергә эшли торган хезмәттәшләреңне хөрмәт итү юк дәрәҗәсендә. Яшьрәк вакытта күбебез картлык килмәс, мин һаман да яшь булырмын, дип уйлый. Җинаятьчелек, наркомания чамадан тыш. Адәм баласы Җир йөзенә кунакка гына килгәнен онытмасын иде. Шул кыска гына гомере иманлы булып, лаеклы яшәп үткәрик. Кешене иман ныклыгы, өмет, ышаныч, мәхәббәт дигән бөек көч яшәтә, шул егәр бирә.

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш шәһәре**

## "Алтын урта" акция уздырды

**20-23 октябрь көннәрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Алтын урта" мөселман яшьләре берлеге "Корбан гаете мөбарәк булсын!" дип аталган акция уздырды.**

Әлеге чара республикабызның төрле районнарында башланып китеп, иң соңыннан, 23 октябрьдә, Казанда үткәрелде. Акциядә "Алтын урта"ның Лениногорск, Бөгелмә, Мамадыш, Яңа Чишмә, Буа һәм Казандагы бүлекләре катнашты. Шулай итеп чарадан шәһәр урамнары да, авыл урамнары да читтә калмады.

Оештыручылар "Алтын урта", нәзарәт логотиплары төшерелгән бертөсле яшел футболкалар киеп, билгеле бер урыннарда мөфти Илдус хәзрәтнең Корбан бәйрәме белән котлавы һәм Корбан чалу тәртибе, гомумән, әлеге бәйрәмне уздыруга кагылышлы мәгълүмат язылган буклетларны таратты. Яшьләрнең мөбарәк бәйрәмебез белән котлавын бигрәк тә өлкән буын кешеләре күңелләренә бик җылы кабул итте.

Казанныкылар башта нәзарәттә җыелдылар. Бирелдә мөфти вазифаларын вакытлыча башкаручы Габдулла хәзрәт яшь мөселманнар белән очрашты һәм аларга Корбан бәйрәме турында вәгазь сөйләде.

Чараны оештыручылар үз алларына мөселманнарны күркәм бәйрәм белән котлауны һәм һәркем үзе корбан чалуда катнашсын өчен бу гамәлне ничек башкару турында мәгълүмат таратуны максат итеп куйганнар иде. Үзең корбан чалуның савабы зуррак, диләр дин әһелләре.

Әлеге чара дини бәйрәмнәр уңаеннан "Алтын урта" тарафыннан оештырылган беренче генә акция түгел. Мөселман яшьләре оешмасы зурая барып, үзенең филиалларын республика районнарында да булдыруга, яшь мөселманнарны күбрәк җәлеп итүгә йөз тота.




*Чарадагы барлык күренешләр белән дә www.altinurta.ru сайтында таныша аласыз*

# Идел буенда ислам сәнгатенең башлангыч чоры үзенчәлекләре

*(Дәвамы. Башы 2 нче биттә.)*

гәүдәләнә.

X-XII гасырларда сәнгать шактый завыклы шәһәр һөнәрчелеге һәм, шәһәр һәм авылларның массакүләм сәнгатенең үзара тәэсирләшүе белән үскән. Шәһәрнең сәнгати һөнәрчелегендә мөселман эстетикасы өчен хас булган бизәкле стиль һәм декор принциплары барлыкка килә. Ә халыкның архаиклашкан сәнгатендә фольклор традицияләре өчен хас булган образлы карашлар гәүдәләнгән. Мөселман сәнгате үсешендә төп роль хакимлек иткән югары катлам һәм дәүләтнең ислам кабул иткән халкы зәвыгын чагылдырган шәһәр сәнгати һөнәрчелегенә туры килгән. Шәһәр һөнәрчеләре эшләрендә орнаменталь стилизация һәм сәнгать теленең шартлылыгына юнәлтелгән гомуммөселман мәдәнияте үсешен чагылдырган стиль тенденцияләренең йогынтысы сизелә.



*Атка атланган кеше сурәте төшкән көзге (VII-IX гасырлар)*

Сәнгатьтә декоративлык принцибы, мөселман дәвере рәссамнарның дөньяга яңача карашы барлыкка килә. Болгар сәнгате әсәрләрендә әкренләп яңа образлылык барлыкка килү процессы күзәтелә. Шуның нәтиҗәсендә мәҗүси фикер йөртүләрнең иске мифологемалары кире кагыла һәм ислам эстетикасы белән бәйле дөньяга яңа караш кабул ителә. Архаиклашып баручы мотив һәм сюжетлар тагын да стильләшеп һәм гомумиләшеп, мөселман сәнгатенең шартлы декоратив иҗат формасына кушылып китәләр. Бу аларның, дөньяга мәҗүсилек күзлегеннән карау өчен хас булган элеккеге эчтәлекләрен югалтуны дәлилли.

Сәнгатьнең мөселман эстетикасы кысаларында Урта гасырлар символизмына таба эволюция ясавы Идел болгарларының декоратив-гамәли сәнгатенең образлы системасын ачып бирә. Бу сәнгать әсәрләре өчен борынгы төрки сюжетларны кабатлау - җанварлар, кошлар, фантастик җан ияләре, һәм бик сирәк кенә очракларда, кеше образлары хас. Алар барысы да мөселман сәнгатенең сурәтләү шартларына хас булган чагылышта ясалган һәм төшерелгән бизәкнең бер өлеше булып торалар. Әгәр дә башлангыч болгар чорында (VIII-IX гасырларда) орнамент бары тик корал, ат кирәк-яраклары, киемдәге һәм баш киемнәрендәге төрле куелмаларны гына бизәгән булса, X-XI гасырлар сәнгатендә ул Идел болгарларының бар матди мәдәниятендә дә диярлек урын ала. Орнамент зооморф, үсемлек һәм геометрик мотивлардан тора. Аның өчен сурәтләрдә бизәклелек, яссылык, кәкре сызыклылык, формаларның түгәрәклеге, контурлылык (силуэтлылык) принципларын куллану хас. Ә XI гасыр азагыннан башлап чәчәк-үсемлек орнаменты өстенлек итә, гарәп хәрефләре кулланылган һәм арабеска (үрелгән геометрик һәм үсемлек) тибындагы бизәкләр дә барлыкка килә.

Болгар осталарының сәнгать теле үзенчәлеге өс киемен бизәү белән бәйле (төрле куелмалар, аеллар, җыелма билбауларга элмә каешлар, хатын-кызлар киемнәрендәге бизәкләр, каптырмалар) һәм көнкүреш (йозаклар, көзгеләр, товарларга сугыла торган мөһерләр), эш һәм сугыш коралларында (балталар, камчылар, чукмар саплары һ. б.) ачыла.

Аларда еш кына бизәү рәсеме итеп Исламга кадәрге чорларга хас булган хайван сурәтләре урнаштырыла. Алар төшерелә торган предметларның контурларына кулай урнашалар, яссы, график формада, ә кайчак күләмле, скульптур рәвештә дә сурәтләнәләр. Ләкин, һәр очракта да, аларда бизәү элементлары стильләштерү, шартлылык, схема рәвешендә саклана.

*(Ахыры киләсе санда.)*

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,**
**сәнгать фәннәре докторы,**
**Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 27.10.12 | 6:10 | 7:40 | 13:02 | 15:50 | 17:14 | 18:44 |
| Якшәмбе | 28.10.12 | 6:12 | 7:42 | 13:02 | 15:49 | 17:12 | 18:42 |
| Дүшәмбе | 29.10.12 | 6:14 | 7:44 | 13:02 | 15:47 | 17:10 | 18:40 |
| Сишәмбе | 30.10.12 | 6:16 | 7:46 | 13:02 | 15:45 | 17:07 | 18:37 |
| Чәршәмбе | 31.10.12 | 6:18 | 7:48 | 13:02 | 15:44 | 17:05 | 18:35 |
| Пәнҗешәмбе | 1.11.12 | 6:21 | 7:51 | 13:02 | 15:43 | 17:03 | 18:33 |
| Җомга | 2.11.12 | 6:23 | 7:53 | 13:02 | 15:41 | 17:01 | 18:31 |
| Шимбә | 3.11.12 | 6:25 | 7:55 | 13:02 | 15:40 | 16:59 | 18:29 |




# МӘДРӘСӘ МӨГАЛЛИМӘЛӘРЕНДӘ ӘДӘП-ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘСЕ

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

үзләренең аңлап бетермәүләре аркасында, шулай итеп уйлый, шулай итеп әйтә дә. Бу - кешенең үз-үзенә эшләгән явызлыгы. Бу турыда беренче дәрестә үк сөйләргә кирәк, чөнки икенчесенә күпләр килми дә калырга мөмкиннәр. Дога турындагы дәрес кешене мәчеткә "бәйләп" куя торган чылбыр ул. Беркем дә, хәтта, мин мәчеттән бик ерак торам дип исәпләгән кеше дә догасыз яшәми.

Доганы, үзеңә дә, туганнарыңа да зыян салмый торган итеп ничек төзергә кирәк икәнен белү һәркем өчен дә мөһим. Зур файда белән үткән беренче дәрес, кешене икенче һәм өченче дәресләргә "чакыра".

Шунысы кызыклы, гарәп телендәге "акыл" сүзе бәйне, дөя муенына бәйләп куела торган бауны аңлата. Шуңа охшаш рәвештә, шул ук гарәп сүзе булган "хикмәт" тә - "авызлык" сүзеннән барлыкка килгән. Мәкальне искә төшерик: "Акылы булган - аңлар, хикмәткә ия булган - юлдан таймас".

Акыл телне бәйдә тотарга тиеш. Кемдә мондый сыйфат бар, аны димәк, сөйләшү культурасына, аралашу ысулларына, диалог нигезләренә өйрәткәннәр дигән сүз.

Телгә табигыйлек бирә торган тагын берничә кагыйдәне карап китик. Бу кагыйдәләрне без, үзебез дә аңлап бетермичә, көн саен кулланабыз.

Беренче кагыйдә: мөһим сүзләрне аерып алыгыз һәм мөһим булмаганнарын аның мәгънә буйсынуына куегыз.

Сөйләшкән вакытта без бер иҗеккә басым ясыйбыз да, калган иҗекләрне тиз генә үтеп китәбез. Шундый ук хәл җөмләдә дә кабатлана. Монда бернидән дә сәерсенергә кирәк түгел. Бу - бар төштә дә таралган гадәти күренеш.

Икенче кагыйдә: модуляцияләр кулланып сөйләшегез.

Сөйләшкән вакытта аның тоны, һәр вакытта да бер биеклектә генә тормыйча, диңгез өслеге кебек үзгәреп, я күтәрелә, я төшә. Ә ни өчен алай соң? Беркемнең дә бу турыда уйланганы юк. Тавыш шулай ягымлырак яңгырый, һәм бу үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Югары тональлектәге монотон тавыш эчне пошыра һәм ялыктыра. Моңа юл куймаска кирәк. Тавышны кискен генә күтәрү яки төшерү юлы белән теләсә нинди фразаны, бакчага утыртылган декоратив агач кебек, контексттан аерып күрсәтергә була.

Өченче кагыйдә: сөйләмегезнең темпын үзгәртеп алыгыз.

Без үзебез, көн саен аралашып сөйләшкән вакытта, безнең сөйләшү темпы гел үзгәреп тора. Бу сөйләмнең тәэсирлелеген арттыра. Бу - үз фикереңне ассызыклау өчен иң яхшы ысулларның берсе. Бу вакытта зур мәгънәгә ия булмаган сүз һәм гыйбарәләрне тиз генә әйтеп китеп, ә ассызыклап күрсәтергә кирәк булган сүзләргә яки фразаларга җиткәч, бу сүз яки фразага басым ясап темпны киметергә, ә аннан соң, тагын бик тиз генә фразаны бетереп куярга кирәк. Ассызыклап аерып күрсәтергә кирәк булган бер яки берничә сүзне әйтү өчен киткән вакыт - калган барысын да әйтер өчен киткән вакыт кадәр булырга тиеш.

Күнегү: "Бик аз сумма турында сүз барган кебек итеп, тизәйткеч рәвешендә: "Ә ... утыз миллион доллар", - дип әйтегез". Ә аннан соң, әкрен генә, тирән хис белән, гаять зур күләмле акча турында сүз барган кебек итеп: "Утыз мең сум", - диегез. Утыз мең сум, утыз миллион долларга караганда, күпкә тәэсирлерәк, зуррак булып яңгырый, шулай түгелме?

Дүртенче кагыйдә: Мөһим фикерләрдән соң пауза эшләгез.

Көтмәгәндә генә килеп чыккан тынлык, көтмәгәндә килеп чыккан шау-шу кебек үк нәтиҗәгә ия, ул тыңлаучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Барысы да, тагын ни әйтелер микән дип көтә башлый. Пауза әйтелгәннең әһәмиятен арттыра һәм укучыларга аны, ул әйтелгәнне, тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Эндәшми торуның, бу очракта вакытлы гына эндәшми торуның, чынлап та алтын икәнлегенә без тагын бер тапкыр инанабыз. Бу - тел чараларының, әһәмиятенә бәя бирүне искә алмый калдырырга тиеш булмаган бик куәтле чарасы. Кайда һәм күпме паузалар эшләргә? Бу дәрес текстының мәгънәсе, укытучының каефе һәм темпераменты белән билгеләнә.

Бишенче кагыйдә: дәреснең мөһим фикерләрен ике-өч тапкыр, төрле җөмләләр кулланып, кабатлап әйтегез.

Бу исә мөһим булган моментларны ныграк хәтердә калдырырга ярдәм итә. Беренче тапкыр әйткәндә, бәлки, ишетми калгандыр, я колак кырыннан үткәреп җибәргәндер, аңлап та бетмәгәндер; икенче тапкыр әйткән вакытта - ишеткән һәм аңлаган; өченче тапкырында инде - таныш булган фикерне хәтерендә калдырган.

Алда әйтеп кителгәннәрдән берничә нәтиҗә чыгарырга була. Алда китерелгән бар кагыйдәләрне дә кулланып, яхшы куелган сөйләм теле мөгаллимәгә төрле яшьтәге талибәләр белән бер-берсен яхшы аңлап сөйләшергә мөмкинлек бирә. Бу методика яхшы нәтиҗәләргә китерә. Анда динамика, ритм бар. Ул укучыларны хәрәкәт итәргә этәрә. Мондый дәресләр вакытында талибәләр мөгаллимәләренең артыннан калмый, аның үкчәсенә басып киләләр, күбрәк һәм һаман да күбрәк белергә телиләр. Һәм дә бу алга таба ислам буенча бик яхшы белемнәргә ия булуга китерә.

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы,**
**Урыссудагы "Фәнис" мәдрәсәсе директоры**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 17 (160) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9422.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 25 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллланудан сакланыгыз!**